ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан куелган мәсьәләләр буенча, хисап бирү хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының $190^{2}$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән мәсьәләләр исемлеген Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 19 гыйнвары
№ 1795-VI ДС

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2023 елның 19 гыйнварындагы 1795-VI ДС номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге**

*Икътисад, бюджет*

1. Импортны алмаштыру шартларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә системалы эшне оештыру турында.
2. Республикада интернет сәүдәне үстерү динамикасы һәм аның перспективалары хакында.
3. Татарстан Республикасы бюджетының керем базасын саклап калу буенча республикада күрелә торган чаралар турында.
4. Татарстан Республикасының кече шәһәрләрендә шәһәр эче юлларын капиталь ремонтлау чараларын финанслау хакында.
5. 2023 елда республиканың муниципаль районнарында сәнәгать парклары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру программасы кысаларында йөкләнеш күрсәткечләре түбән булган сәнәгать паркларын алга таба үстерү перспективалары турында.
6. Республикада капитал салуларны яклау һәм хуплау турында килешүләр төзү механизмнарын алга җибәрү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан күрелә торган чаралар хакында. Аларда нинди инвестиция проектлары катнашачак?
7. Татарстан Республикасында энергетиканы модернизацияләүгә юнәлдерелгән һәм кабул ителгән тышкы санкцияләргә һәм технологик чикләүләргә бәйле рәвештә туктатылган проектларны гамәлгә ашыру перспективалары турында.
8. Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын үткәрү йомгаклары хакында.
9. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыру темпларын саклап калу өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан күрелә торган чаралар турында.

10. 2023 елда инфраструктура бюджет кредитлары акчаларыннан файдаланып инфраструктура проектларын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте планнары хакында (төзелеш объектлары турындагы мәгълүматны кертеп).

*Социаль сәясәт*

11. Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча үткәрелә торган эш хакында.

12. Татарстан Республикасында социаль газлаштырып бетерү программасын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чаралар турында.

13. Торак-коммуналь хуҗалык тарифлары, җәмәгать транспортында йөргән өчен тарифлар үсешен туктатып торуга һәм халыкка транспортта хезмәт күрсәтү сыйфатын арттыруга юнәлдерелгән чаралар хакында.

14. Күпбалалы гаиләләргә өченче бала туганда бүлеп бирелгән җир кишәрлекләрен үзләштерү проблемасын хәл кылуда ярдәм итү турында.

15. Демографик вәзгыятьне яхшыртуга, шул исәптән үлүчеләр санын киметү юлы белән дә, юнәлдерелгән чаралар хакында.

*Сәламәтлек саклау*

16. Санкцияләр шартларында республикада дәвалау учреждениеләрен медицина җиһазлары һәм медикаментлар белән тәэмин итү буенча үткәрелә торган эш турында.

17. Республиканың эре шәһәрләрендәге яңа микрорайоннар территорияләрендә сәламәтлек саклауның яңа учреждениеләрен (хастаханәләрен, поликлиникаларын) төзү (ачу) барышы, Казан шәһәрендә 1 нче балалар күппрофильле хастаханәсенең яңа бинасын төзү перспективалары хакында.

18. Татарстан Республикасы халкын республиканың шифаханә-курорт учреждениеләрендә дәвалауны дәвам итүгә (реабилитацияләүгә) финанс чыгымнары нормативларын арттыру планлаштырыламы?

19. Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында физик культура белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру турындагы мәсьәләне хәл итү перспективалары хакында (шул исәптән спорт заллары төзү, иске биналарда урнашкан шәһәр мәктәпләренең спорт залларына капиталь ремонт үткәрү турында).

20. Татарстан Республикасында мәктәп медицинасын үстерү өчен шартлар тудыру хакында.

*Мәгариф, мәдәният*

21. Татарстан Республикасында гражданнарны патриотик тәрбияләү эше турында.

22. Педагогик хезмәткәрләргә ярдәм итү һәм кызыксындыру чаралары хакында.

23. Татарстан Республикасында халык сәнгать һөнәрләренә һәм кәсепләренә ярдәм итү һәм кызыксындыру чаралары турында.

24. Татарстан Республикасында «Пушкин картасы» проектын гамәлгә ашыру хакында.

25. Республиканың эре шәһәрләрендәге яңа торак микрорайоннары территориясендә мәгариф учреждениеләрен төзү перспективалары турында.

26. Казан шәһәрендә Абдулла Алиш исемендәге Балалар иҗат сараен капиталь ремонтлау перспективалары хакында.

27. Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары һәм муниципаль мәгариф оешмалары тарафыннан өйдә укыту оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларны ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин итү турында.

*Иҗтимагый иминлек*

28. Татарстан Республикасында, аерым алганда, Казан шәһәрендә, гражданнарны, шулай ук аларның берләшмәләрен иҗтимагый тәртип саклауда катнашуга җәлеп итү буенча күрелә торган чаралар хакында.

29. Татарстан Республикасында юл-транспорт һәлакәтләрен һәм юлларда һәлак булу очракларын киметү буенча күрелә торган чаралар турында.

30. Татарстан Республикасында торак йортларда һәм гражданнар күпләп була торган урыннарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча күрелә торган чаралар хакында.

31. Татарстан Республикасында мәгариф учреждениеләрендә балаларның иминлеген тәэмин итү һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны киметү буенча күрелә торган чаралар турында.

32. Гадәттән тыш хәлләр очрагында халыкны яклауга юнәлдерелгән чаралар хакында. Халыкка хәбәр итүнең локаль системаларын торгызуга юнәлдерелгән чаралар турында.

*Экология*

33. «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законны хайваннар өчен приютлар булдыру өлешендә үтәү барышы турында.

*Җирле үзидарә мәсьәләләре*

34. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән инициатив проектларны гамәлгә ашыру перспективалары хакында.

35. Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне цифрлаштыру турында.

36. Муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен арттыру чаралары хакында.